

18 майда Рузаевка районы Татар Пешлә авылынын якташыбыз Шәриф Камал исемен йорткән мәктәптә Татарстаннан шагыйрь Ләбиб Лерон белән «Безнен мирас» журналынын баш мохәррире Ленар Гобәйдуллин кунакта булганнар.
Кунаклар башта Ләмберә районы Аксён авылын килеп кvргәннәр. Аннары Мордовиядә булып та Шәриф Камал туган ягында булмый кайтырга теләмәгәннәр: Рузаевка районына юлланганнар. Бу аларнын кvптәнге теләге булган икән.      Шәриф Камал исемендәге Татар Пешлә авылы мәктәбе директоры Флора Ахметжан кызы Шамонова белән татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сания Спартак кызы Саляева кунакларны каршы алып матур аралашалар, мәктәп буенча экскурсия ясыйлар. Мәктәп укучылары белән очрашып, тирән эчтәлекле әнгәмә vткәрәләр. Бvләккә «Безнен мирас», «Казан утлары», «Ялкын», «Идел», «Мәйдан» журналынын торле саннарын алып килгәннәр.
 - Мәшһvребез Шәриф Камалны доньяга индергән гvзәл табигатьле Татар Пешләсендә тәvге булуыбыз. Авыл - искитмәле зур икән! Янгыр явып торганда килеп кердек авылга – быел унышлы ел булыр, Аллах бирса!
Музей бик кvркәм, алга таба тагы да мәртәбәле булса иде, булыр иншалла, дигән теләктә калабыз.
Мәктәп укытучыларына ин изге теләкләребез! Авыл яшәсен, мәктәп бетмәсен, халкы исән-сау булсын, Амин!
Ихтирам белән шагыйрь Ләбиб Лерон, «Безнен мирас» журналынын баш мохәррире Ленар Гобәйдуллин, дип истәлек язмаларын да калдырганнар.

**Наилә НАСЫРОВА**